**Тукай муниципаль районы**
**Түбән Суык-Су авыл җирлеге**
**Түбән Суык-Су авылы**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

25 ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Түбән Суык-Су авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1 500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу.
- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү (Г.Тукай ис.ур., Мазино).
- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу.
- Су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре).
- Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту).
- Үзәк урамы территориясен төзекләндерү (агачларны кисү).
- Коймалар сатып алу һәм Новая урамы буенча урнаштыру.
- Күлне камышлардан чистарту.
- Зиратны төзекләндерү (материаллар сатып алу, койма ясау һәм урнаштыру).
- Янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә).
- Белорус тракторына җиһазлар (чапкыч, отвал, щетка) сатып алу.

2. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Ихсанов